| СОВЕТ ПЕЧИЩИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ПЕЧИЩИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

| РЕШЕНИЕ | | КАРАР |
|---|---|---|
| 17.01.2022 | с. Печищи | № 16-86 |

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлегенең 2021нче елгы бюджеты үтәлеше турында хисап

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге башлыгы Яковлев Леонтий Владимирович мәгълүматын тыңлаганнан һәм тикшергәннән соң,

Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге Советы
Карар итте:

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлегенең 2021 нче елгы бюджеты үтәлеше турында хисапны игътибарга алырга.

Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында халыкка җиткерергә һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге башлыгы Л.В. Яковлев

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге Советының
17.01.2022 ел, 16-86 карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлегенең 2021нче елгы бюджеты үтәлеше турында хисап

Печищи авыл җирлегенең 2021 елга бюджеты, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертеп, 3237,5 мең сум күләмендә расланды, шуларның 3237,5 мең сум

- 567,4 мең сум - үз керемнәре, бу 17,5% тәшкил итә

- 2670,1 мең сум дотация.

Млн.сум.

| | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 |
|---|---|---|---|---|
| Үз керемнәре, мең сум. | 0,9 | 0,9 | 0,8 | 0,56 |
| Дотацияләр, мең сум. | 2,85 | 2,85 | 2593,2 | 2670,1 |
| Нисбәт | 24,0 | 24,2 | 25,3 | 17,5 |

Җирлек бюджеты дотацияле,үз керемнәре минималь чыгымнарны да капламый. Бу район җирлекләренең үз-үзләрен тәэмин итү буенча иң түбән күрсәткечләрнең берсе.

Печищи авыл җирлегенең үз керемнәре түбәндәге керемнәр хисабына формалаша:
- НДФЛ-план үтәлеше 116,9% ка (план 66,0 мең сум булганда 77,1 мең сум)
- милеккә салым 228,8% ка (план 150,0 мең сум булганда 343,1 мең сум)
- җир салымы 228,8 % ка үтәлгән (план буенча 150,0 мең сум).

Үз керемнәре структурасы:

| исеме | план | Факт | % |
|---|---|---|---|
| физик затлар кеременә салым | 66,0 | 77,1 | 116,9 |
| физик затлар милкенә салым | 127,4 | 186,8 | 146,7 |
| җир салымы | 150,0 | 343,1 | 228,8 |
| мөлкәтне арендалау | 24,0 | 17,2 | 71,7 |
| түләүле хезмәтләр һәм чыгымнарны кайтару(завод электр энергиясе) | 200,0 | 70,0 | 35,0 |
| | 567,4 | 694,2 | 122,0 |

Бюджетның чыгым өлеше, план буенча 3383,7 мең сум булган очракта, 3280,1 мең сум тәшкил итте һәм үтәлеше 97,0% тәшкил итте %,

2021 ел өчен төп чыгымнар

| исеме | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 |
|---|---|---|---|---|
| Электр энергиясе, | 630,2 | 778,3 | 723 | 883 |
| шул исәптән | 167,4 | 174,4 | 114 | 94,2 |
| | 282,2 | 405,7 | 411 | 634 |
| - урамнарны яктырту | 253,0 | 254,1 | 438,4 | 462,8 |
| - су суырту | | | 14,4 | |
| Юлларны карап тоту, | 183,7 | 144,0 | 170 | 293,3 |
| шул исәптән | 3<br>0,8 | 4<br>9,9 | 1<br>39,2 | 1<br>62,5 |
| - юлларга сибү өчен тоз сатып алу | 1<br>1,2 | | 4<br>5,6 | 7<br>,0 |

Урамнарны яктырту буенча электр энергиясенең экономияләнүен билгеләп үтәсем килә. Бу урам яктырткычлары фонарьларын энергия саклый торган, шул исәптән үзара салым кысаларында алыштыру буенча эшләр башкарганнан соң мөмкин булды. 2021 ел нәтиҗәләре буенча 1 фонарьга елына 438 сум китә. 2018 елда әлеге сумма 1670 сумга тиң иде.

2022 елга авыл җирлегенең бюджеты керемнәр буенча 2348,49 мең сум күләмендә расланган. 2022 елга үз керемнәре 653,6 сум тәшкил итә-расланган бюджетның 27,8%

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге башлыгы Л.В. Яковлев